Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы
Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

№10 **23.12.2025 ел**

«Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» 2018 елның 23 апрелендәге 107 номерлы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 2 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елның 23 апрелендәге 107 номерлы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советының «Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында» карарына (24.05.2018 ел №109, 23.11.2018 ел №131, 07.12.2018 ел №138, 22.09.2020 ел №5, 30.12.2021 ел №50, 30.09.2022 ел №75, 22.11.2022 ел №80, 02.03.2023 ел №97, 24.06.2024 ел №136, 10.12.2024 ел №152, 07.05.2025 ел №174 Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советының үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә:

2.2 пунктта «15 389 сум» сүзен «16 928 сум» сүзе белән алыштырырга;

2.14 пунктта «15 389 сум» сүзен «16 928 сум» сүзе белән алыштырырга.

1.2. Әлеге карар белән расланган Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дүрт-Мунча авыл җирлеге башлыгына акчалата түләү күләме

Вазыйфаның исеме	Акчалата түләү күләме (сумнарда)
Муниципаль берәмлек башлыгы	23 201

2. Карарны Дүрт-Мунча авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Дүрт-Мунча авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе **Р.Т.Ситдиков**